**Яр Чаллы шәһәре Хакиме**
**карары**

**№М 83**
**20.02.2021**

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең хокук бозуларны профилактикалау буенча ведомствоара комиссиясе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә коралның, сугыш припасларының, коралга патроннарның, шартлаткыч җайланмаларның һәм шартлаучан матдәләрнең законсыз әйләнештә йөрүен кисәтү чаралары турында» 1995 елның 5 августындагы 545 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 28 декабрендәге 1209 номерлы карары, Шәһәр Уставының 53 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Шәһәр Хакименең «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең хокук бозуларны профилактикалау буенча ведомствоара комиссиясе турында» 2011 елның 11 мартындагы 150 номерлы карары (шәһәр Хакименең 2020 елның 21 июлендәге М 255 номерлы, 2020 елның 21 сентябрендәге М 331 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең хокук бозуларны профилактикалау буенча ведомствоара комиссиясе турында нигезләмәгә, 3 пунктның 7 пунктчасын төшереп калдырып, үзгәрешләр кертергә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев